ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21 апрель 2017 ел № 2465

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә
җирләү эшен оештыру турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе 1 бүлегенең 23 пункты, Россия Федерациясендә җирләү һәм зиратларны карап тоту тәртибе турында тәкъдимнәр МДК 11-01.2002, РФ Баш дәүләт санитария табибының 2011 елның 28 июнендәге 84 нче Карары белән расланган «Зиратларны, җирләү билгеләнешендәге биналарны һәм корылмаларны урнаштыруга, булдыруга һәм карап тотуга карата гигиена таләпләре» СанПиН 2.1.2882-11, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 21 апрелендәге
2465 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге тәртип «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясендә җирләү һәм зиратларны карап тоту тәртибе турында тәкъдимнәр МДК 11-01.2002, РФ Баш дәүләт санитария табибының 2011 елның 28 июнендәге 84 нче Карары белән расланган «Зиратларны, җирләү билгеләнешендәге биналарны һәм корылмаларны урнаштыруга, булдыруга һәм карап тотуга карата гигиена таләпләре» СанПиН 2.1.2882-11, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

2. Әлеге тәртип вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын), көлен күмү (кабат күмү) белән бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала, Яр Чаллы шәһәрендә гамәлдәге һәм яңа барлыкка килгән барлык зиратлар территориясендә җирләү эшен оештыру нигезләрен, җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләрен билгели.

3. Әлеге тәртип Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге барлык зиратларга да кагыла һәм оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә барлык хуҗалык итүче субъектлар, шулай ук анда килүче гражданнар тарафыннан үтәү өчен мәҗбүри.

4. Зират – вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын), көлен күмү өчен билгеләнгән җирләү билгеләнешендәге объект, шулай ук үлгәннәрне күмүне һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән биналар, корылмалар һәм башка объектлар.

5. Күмү урыннары биләп торган һәм җирләүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән җир участоклары зиратның җирләү зонасын тәшкил итә. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге зиратлары муниципаль милек булып тора.

6. Зиратның янәшә территориясендә административ-хуҗалык, энергетика һәм ярдәмче билгеләнештәге яңа объектлар, гыйбадәт корылмалары, парковка зоналары урнаштырылырга, төзелергә һәм гамәлдәгеләре реконструкцияләнергә мөмкин. Күмү урыны булып саналмаган җирләү билгеләнешендәге территорияләр һәм объектлар, Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше законнарындагы таләпләр нигезендә, зиратның мөлкәт комплексын формалаштыралар.

Башка хужалык субъектлары карамагындагы төзелешләр өчен жир участоклары үзенә аерымланган булып тора, алар уникаль кадастр номерына ия һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган хокукта һәм срокка бирелә.

7. Вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын) күмү (алга таба – вафат булганнарны күмү) вафат (һәлак) булганнарның гәүдәсенә игътибарлы мөнәсәбәт булдыру һәм халыкның санитария-эпидемиология иминлеген тәэмин итү, вафат булучының Яр Чаллы шәһәре зиратында күмелгән булуга хокуклары гарантиясен тәэмин итү максатларында башкарыла.

8. Яр Чаллы шәһәре зиратларында вафат булганнарны күмү, мәет калдыкларын эксгумацияләү, кабер өсте корылмаларын урнаштыру (алыштыру) буенча эшләр, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан расланган тәртип нигезендә, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты шәһәр хужалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең (алга таба – вәкаләтле орган) карары буенча башкарыла.

## 2 бүлек. Зиратларны төзекләндерүгә һәм аларның эшләрен оештыруга төп таләпләр

9. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге зиратлары – муниципаль, гореф-гадәтләр буенча – ижтимагый, җирләү тибы буенча традицион һәм дини булып тора.

10. Яр Чаллы шәһәре зиратлары җирләүне гамәлгә ашыру буенча өч типка бүленергә мөмкин: ачык, ирекле җирләү өчен ябык һәм ябык.

Ачык зиратлар – җирләү чикләүләрсез гамәлгә ашырыла торган яңа җирләү урыннары булдыру өчен жир участоклары булган зиратлар.

Ирекле җирләү өчен ябык зират – яңа җирләү урыннары булдыру өчен буш жир участоклары булмаган, ә гамәлдәге каберләрдә урыннар булганда җирләү гамәлгә ашырыла торган зиратлар.

Ябык зиратлар – вафат булганнарны җирләү гамәлгә ашырылмый торган зиратлар.

Зиратның статусы турындагы карар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

10. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге зиратларны төзекләндерү, аларны тиешле тәртиптә карап тоту, җирләүнең санитария нормаларын үтәү, кирәкле хезмәт күрсәтүче персонал белән тәэмин итү җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарыла.

11. Яңа җирләү урыннары (яңа зиратлар) булдыру турында карар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән кабул ителә.

12. Җирләү ысулына бәйсез рәвештә, зират территориясен функциональ зоналарга бүләләр:

1) керү;

2) ритуаль;

3) административ-хужалык;

4) җирләү зонасы;

5) зират периметры буенча яшел саклык зонасы.

13. Зиратларның мәйданы 10 га һәм аннан зуррак булган керү зонасында түбәндәгеләр күздә тотылырга тиеш:

1) зиратның һәм җирләү эшен оештыру өчен вәкаләтле органның исеме күрсәтелгән керү урыны (транспорт һәм килүчеләр өчен аерым керү-чыгу урыны);

2) керү урынын яктырту;

3) хуҗалык өчен аерым керү урыны;

4) чүп җыю өчен урналар;

5) административ биналар, участоклар, юллар, тарихи һәм мемориаль каберләр, гомуми файдалану урыннары һәм суүткәргеч краннар (техник ихтыяҗлар өчен су җыю баклары) билгеләнгән схематик план;

6) администрация белдерүләрен һәм боерыкларын, зиратларга килү кагыйдәләрен, гражданнарның хокукларын һәм бурычларын урнаштыру өчен беленмә-мәгълүмат стенды;

7) җәмәгать бәдрәфләре.

Керү зонасында башка җирләү сервисы объектлары һәм килүчеләргә ял урыннары урнаштырылырга мөмкин.

14. Траур процессияләренең тоткарлыксыз үтүе өчен зиратлардагы капкаларның киңлеге 4,0 метрдан ким булырга тиеш түгел. Кечкенә капканың киңлеге 1,2 метрдан ким булырга тиеш түгел.

15. Зратларның ритуаль зоналары төп керү урынына һәм административ-хуҗалык зонасына якында урнаштырылырга тиеш.

Ритуаль зонада траур йолалары үткәрү һәм хушлашу өчен биналар һәм корылмалар, гыйбадәт биналары һәм корылмалары, иҗтимагый билгеләнештәге һәйкәлләр, ял итү өчен япмалы мәйданчыклар, урналар бирү залы күздә тотыла.

Җәмәгать зиратларының хәрбиләрне җирләү секторларында хәрби хөрмәт күрсәтү мәйданчыклары күздә тотылырга тиеш.

16. Административ-хуҗалык зонасы – зират территориясенең административ-көнкүреш бинасы, материал һәм инвентарь складлары урнаштырыла торган өлеше. Аның өчен аерым керү урыны күздә тотыла.

17. Зиратлар түбәндәгеләр белән җиһазландырылырга тиеш:

1) чүп җыю контейнерлары булган мәйданчыклар;

2) су сибү өчен суүткәргечләр яки техник ихтыяҗлар өчен су җыю баклары;

3) автомобильләр кую урыны.

18. Зиратлар территориясе койма белән тотып алынырга тиеш.

19. Җирләү зонасы зиратның төп функциональ өлеше булып тора һәм квартал баганаларында күрсәтелгән тиешле хәрефләр һәм цифрлар белән билгеләнгән кварталлар, секторлар һәм участокларга бүленә.

Барлык тип зиратлардагы җирләү зоналарының мәйданы зиратның гомуми мәйданының кимендә 65-75 % ын тәшкил итәргә тиеш.

Җирләү урыннарының кварталлары, секторлары һәм участоклары җирләү зонасының планлаштыру структурасы элементлары булып тора.

Кварталлар киңлеге 1,2 метрдан ким булмаган каты түшәлмәле эчке юллар белән бүленә. Кварталлар эчендәге секторлар киңлеге 1,2 метрдан ким булмаган каты түшәлмәле аллеялар белән бүленә.

Зиратларның эчке юлларын һәм аллеяларын салган вакытта, участоктагы иң ерак кабердән юлга яки аллеяга кадәр ераклык 50 метрдан артык булмау исәпкә алынырга тиеш.

20. Зиратларда ялгызларны җирләү, кардәшләрне җирләү, гаиләләрне (нәсел) җирләү, мактаулы, хәрби, туганнар (гомуми) каберлеге өчен участоклар күздә тотылырга тиеш.

21. Зиратларның периметры буенча хуҗалык әһәмиятендәге божралы (урап узу) юл һәм зиратны визуаль саклауны тәэмин итүче, торак, балалар һәм дәвалау учреждениеләре ягыннан күренмәс өчен мораль (яшел) саклык зонасы урнаштыру тәкъдим ителә.

22. Җирләү урыннарына килү өчен тәкъдим ителә торган вакыт: май-сентябрь айларында – 8.00-19.00 сәгатькә кадәр, октябрь-апрель айларында – 8.00-17.00 сәгатькә кадәр.

Зират администрацияләренең эш режимы – көн саен 8.00-17.00 сәгатькә кадәр.

Яр Чаллы шәһәре зиратларында вафат булганнарны җирләү көн саен 10.00-16.00 сәгатькә кадәр башкарыла.

23. Яр Чаллы шәһәре зиратларын карап тоту кагыйдәләре Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

## 3 бүлек. Зиратларда җирләү урыннары һәм аларның төрләре

24. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең барлык зиратларында да кремацияләнмәгән мәетләрне җирләү (табут белән, табутсыз), санитария-эпидемиология нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә, гореф-гадәтләргә һәм дингә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

25. Җирләү урыннары зиратның билгеләнгән планы нигезендә билгеләнә. Зиратны планлаштыру эшен вәкаләтле орган билгели.

26. Зират территорияләрендә, вафат яки һәлак булганнарны диненә туры китереп җирләү өчен, аерым участоклар яки секцияләр дә булдырылырга, шулай ук җирләү чардуганлы һәм чардугансыз ысул белән дә башкарылырга мөмкин.

27. Җирләү урыннары түбәндәге төрләргә бүленә:

1) ялгызлар;

2) кардәшләр;

3) гаиләләр (нәсел);

4) мактаулы;

5) хәрбиләр;

6) туганнар (гомуми).

Җирләү өчен җир участоклары түләүсез нигездә бирелә.

28. Ялгызларны җирләү урынының үлчәме 2,0 м х 2,0 м х 1,0 м (озынлыгы, тирәнлеге, киңлеге) тәшкил итә.

29. Зират территориясендә кардәшләрне җирләү урыны, вафат булучыны җирләү өчен, шуны ук урында ирен (хатынын) яки якын туганын күмүне

гарантияли алырлык итеп бирелә. Кардәшләрне җирләү урыннары турыдан-туры вафат булучыны күмгәндә бирелә. Кардәшләрне җирләү урынын үз исеменә теркәгән затка киләчәктә әлеге урында күмелү хокукы бирелә, шулай ук җирләү урынында вафат булучының туганнарын күмү рөхсәт ителә.

Кардәшләрне җирләү урыннарында күмү әлеге каберга соңгы тапкыр күмелгән вакыттан соң кимендә 15 ел узганнан соң рөхсәт ителә.

Барлык зиратларда да кардәшләрне күмү урынының үлчәме 2,0 м х 2,5 м х 2,0 м (озынлыгы, тирәнлеге, киңлеге) тәшкил итә.

30. Гражданнарны гаиләләп (нәсел белән) җирләү – ике һәм аннан күбрәк вафат булган якын туганнарны күмү өчен җәмәгать зиратларындагы аерым җир участоклары.

Якын туганнарга ире (хатыны), балалары, ата-аналары, уллыка алынучылар, уллыкка алучылар, бертуган абый яки энеләр, бертуган апа яки сеңелләр, оныклар, бабайлар, әбиләр керә.

31. Гаиләләп җирләү өчен урыннар бирелергә (калдырылырга) мөмкин булган зиратлар исемлеге Башкарма комитет карары белән раслана.

Гражданнарны гаиләләп (нәсел буенча) җирләү урынының үлчәмнәре һәм аннан файдалану тәртибе, Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары нигезендә, Яр Чаллы шәһәренең Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

32. Гаиләләп җирләү урыны булдыруга җир участогы бирү (калдыру) өчен, кызыксынучы зат (гариза бирүче) гаиләләп җирләү урынын алдан билгеләү максатында җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәткә мөрәҗәгать итә һәм гаиләләп җирләү урынын алдан килешенү акты төзелә. Җирләү урынын алдан килешенү актында участокның урнашу урыны (зиратның исеме, квартал, сектор, участок номеры), үлчәме һәм файдалану шартлары (турыдан-туры яки киләчәктә җирләү өчен) күрсәтелә. Алдан килешенү акты ике нөсхәдә төзелә, берсе гариза бирүчегә бирелә.

33. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урын бирү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен вәкаләтле органга түбәндәге документлар тапшырыла:

1) гаиләләп җирләү урынында җирләү (кабат җирләү) күздә тотылган затларны күрсәтеп, гаиләләп җирләү өчен урын бирү турында гариза;

2) паспорт яки гариза бирүченең шәхесен таныклаучы башка документ күчермәсе (төп нөсхәне теркәп);

3) гаризада күрсәтелгән затларның туганлык дәрәҗәсен раслаучы документларның күчермәләре (төп нөсхәләрне теркәп);

4) җирләү урынын алдан килешенү акты.

Әлеге тәртиптә каралмаган башка документларны таләп итү рөхсәт ителми.

Тапшырылган барлык документлар опись буенча кабул ителә, аның күчермәсе, әлеге тәртиптә күрсәтелгән документларны тапшырган көнне кабул итеп алу датасы турында билге куеп, гариза бирүчегә бирелә.

Вәкаләтле орган тапшырылган документларны исәпкә алуны һәм аларның саклануын тәэмин итә.

34. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урын бирү турындагы яки аны бирүне кире кагу турындагы карар, гариза бирүче үлү турында медицина

таныклыгын яки гражданнар хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелә торган үлү турында таныклыкны, шулай ук әлеге тәртипнең 33 пунктында күрсәтелгән документларны җирләү эше мәсьәләләре буенча вәкаләтле органга биргән көнне кабул ителә.

35. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урынның үлчәме (гаиләләп җирләү өчен бушлай бирелә торган урынны исәпкә алып) 12 кв.метрдан артырга тиеш түгел.

36. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен, кардәшләрне җирләүгә бушлай бирелә торган урын күләменнән арткан урын калдыру өчен (алга таба – киләчәктә җирләү өчен урын калдыру) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү алына.

37. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урын бирү турындагы карар әлеге тәртипнең 35 пунктында билгеләнгән срокта гариза бирүчегә тапшырыла яки аны тапшыру турында белдерү кәгазе белән почта аша җибәрелә (алга таба – белдерү кәгазе белән җибәрелә).

38. Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урын бирүне кире кагу турындагы карар, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге тәртипнең 35 пунктында билгеләнгән срокта гариза бирүчегә тапшырыла яки белдерү кәгазе белән җибәрелә.

Гаиләләп (нәсел белән) җирләү өчен урын бирүне кире кагу түбәндәге очракларда рөхсәт ителә:

1) гариза бирүче гаиләләп җирләү өчен урыннар бирү (калдыру) мөмкин булган зиратлар исемлегенә керми торган зиратта урын алу теләге белдергән очракта;

2) гариза бирүче гаиләләп җирләү (урын калдыру) өчен тәкъдим ителгән урыннардан баш тарткан очракта;

3) гариза бирүче, зиратның структур үзенчәлекләре һәм зиратның архитектура-ландшафт мохите белән бәйле рәвештә гаиләләп җирләү (урын калдыру) өчен бирү мөмкин булмаган урынны алу теләге белдергән очракта;

4) гариза бирүче әлеге тәртипнең 34 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта.

Гариза бирүче гаиләләп җирләү өчен урын бирүне (калдыруны) кире кагу белән риза булмыйча, суд тәртибендә шикаять бирергә яисә, гаиләләп җирләү өчен урын бирүне (калдыруны) кире кагу өчен нигез булып торучы шартлар бетерелгәннән соң, гаиләләп җирләү өчен урын бирү турындагы гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

39. Зиратларда мактаулыларны җирләү өчен аерым участоклар күздә тотылырга мөмкин.

40. Мактаулыларны җирләү өчен мәйданы кимендә 5 кв.м булган участокларда күмү дәүләт, иҗтимагый оешмалар һәм гражданнар тәкъдиме буенча башкарыла.

41. Зиратларда Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, шулай ук коралды конфликтларда һәлак булганнарны җирләү өчен аерым участоклар оештырылырга мөмкин. Әлеге участокларда җирләү вафат булучының хәрби хәрәкәтләрдә катнашуын раслаучы документларны күрсәткәндә башкарыла.

42. Яр Чаллы шәһәренең җәмәгать зиратларында вафат булучыларны өстенлекле дини (кофессиональ) билгеләре буенча җирләү өчен участоклар күздә тотылырга мөмкин. Дини зиратлардагы әлеге җирләү урыннарының участокларын исән вакытта бары тик бер дин тоткан вафат булучыларны күмү өчен билгеләнгән җирләү урыннарыннан аерырга кирәк.

## 4 бүлек. Вафат булганнарны җирләү тәртибе

43. Яр Чаллы шәһәре зиратларында вафат булганнарны җирләү вафат булучының гәүдәсен (мәет калдыкларын) җирләү (кабергә, төрбәгә күмү) яки көл салынган урнаны күмү (кабергә, колумбарийга күмү) буенча, этник һәм санитария таләпләренә каршы килми торган гореф-гадәтләр һәм традицияләр нигезендә, вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын), көлен күмү буенча йолалар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

44. Гамәлдәге законнар нигезендә һәр кешегә, аның ихтыярын исәпкә алып, үлгәннән соң күмү, гәүдәне (мәетне) яки көлне күмү өчен бушлай җир участогы бирү гарантияләнә.

Зиратларда вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын) яки көлен күмү урыннары вафат булганнарны җирләүне гамәлгә ашыру өчен бирелә. Әлеге зиратта җирләнмәгән затлар истәлегенә кабер өсте корылмалары урнаштыру рөхсәт ителми.

45. Вафат булганнарны җирләү бары тик гражданнар хәле актларын теркәү буенча вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән дәүләт үрнәгендәге үлү турында таныклык яки билгеләнгән үрнәктәге перинаталь үлем турында медицина таныклыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

46. Яр Чаллы шәһәре зиратларында вафат булганнарны җирләү, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт көче белән яки, вәкаләтле орган ягыннан эшләр үткәрү технологиясен контрольдә тотып, вафат булучыны күмү бурычын үз өстенә алган зат тарафыннан башкарыла.

47. Вафат булучыны күмү өчен җир участогының (җирләү урынының) үлчәме зират статусыннан һәм буш урыннар булудан чыгып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

Участок үлчәме түбәндәгечә:

- 1,2 м х 2,2 м – бер вафат булучыны җирләү өчен;
- 2,5 м х 2,2 м – ике вафат булучыны җирләү өчен яисә, өстәмә урын бирелгән очракта, вафат булган якын туганын күмү өчен.

Кабернең тирәнлеге – 1,5 метрдан ким түгел.

48. Вафат булучыны җирләү өчен яңа (буш) участок бирелгән очракта, дүрт якның берсеннән күмү урыны озынлыгында кабер янына ирекле керү тәэмин ителергә тиеш. Кабер янына ирекле керүне тәэмин итүче юлның киңлеге 0,5 метрдан ким булырга тиеш түгел.

49. Җирләү, кагыйдә буларак, зират территориясеннән рациональ файдалануны исәпкә алып, эзлекле тәртиптә башкарыла. Участок, аның күләме һәм турыдан-туры күмү урыны, вафат булучының һәм вафат булучыны күмү бурычын үз өстенә алган затның ихтыярын исәпкә алып (мөмкинлек булганда), вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

50. Җирләү зиратның буш урыннарында, кардәшләрне күмү өчен билгеләнгән буш урыннарда, шулай ук турыдан-туры гамәлдәге каберләрдә башкарыла.

Вафат булганнарны гамәлдәге каберләргә күмү (алга таба – кабат күмү) бары тик минерализация чоры узганнан соң, әмма соңгы җирләүдән соң кимендә 15 ел узгач гамәлгә ашырыла.

51. Кардәшләрне күмү өчен билгеләнгән буш участокта вафат булганнарны җирләү бары тик элек бирелгән чикләрдә генә рөхсәт ителә.

52. Кардәшләрне күмү өчен билгеләнгән буш урында һәм минерализация чоры узганнан соң вафат булганнарны турыдын-туры гамәлдәге каберләргә җирләү, тиешле документлары булган очракта, җирләү урыны өчен җаваплы гражданнарның гаризасы яки җирләү урыны өчен җаваплы кешенең күмү буенча вазыйфаларын үз өстенә алган затларның гаризалары буенча башкарыла.

Тиешенчә теркәлмәгән яки Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә җирләү урыны өчен җаваплы зат турында исәпкә алу мәгълүматлары вәкаләтле органда булмаган очракта, кардәшләрне күмү өчен билгеләнгән буш урыннарда вафат булганнарны җирләү башкарылмый.

53. Җирләү урыны өчен җаваплы зат вафат булган очракта, аны исән вакытта үзе караган кабергә күмү максатында, аны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган зат әлеге кабергә күмү турында билгеләнгән үрнәктәге таныклыкның төп нөсхәсен вәкаләтле органга бирергә тиеш.

54. Кабер казу, тиешле рөхсәтне алганнан соң, бары тик вәкаләтле орган тарафыннан күрсәтелгән участокта һәм чикләрдә башкарыла.

55. Вафат яки һәлак булганнарның гәүдәсен (мәет калдыкларын), көлен күмү бары тик тиешле рөхсәтне алганнан соң һәм вәкаләтле орган белгечләре контроле буенча башкарыла.

56. Кабер казуга һәм вафат булучыны җирләүгә рөхсәт алу өчен, вафат булучының ихтыярын үтәүче яки вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган зат билгеләнгән үрнәктәге гариза белән вәкаләтле органга шәхсән мөрәҗәгать итә.

57. Гаризага түбәндәге документлар һәм аларның күчермәләре теркәлә:

1) яңа урында җирләгән очракта:

- дәүләт үрнәгендәге үлү турында таныклык яки билгеләнгән үрнәктәге перинаталь үлем турында медицина таныклыгы;

- гариза бирүченең паспорты.

Яңа урында җирләгән очракта гариза, җирләү күздә тотылган урынга барып, зираттагы вәкаләтле орган белгечләре тарафыннан карап тикшерелә, күмүне гамәлгә ашыру мөмкинлеге һәм җирләү урынының урнашу урыны билгеләнә, шуннан соң гаризага тиешле килешенү билгесе куела; җирләү буенча гариза мөрәҗәгать иткәннән соң бер тәүлектән артмаган срокта карап тикшерелә һәм килештерелә.

2) гамәлдәге кабергә кабат җирләгән очракта (гариза бары тик җирләү урыны өчен җаваплы заттан гына кабул ителә):

- үлү турында таныклык яки билгеләнгән үрнәктәге перинаталь үлем турында медицина таныклыгы;

- җирләү урыны өчен җаваплы затның паспорты;

- билгеләнгән тәртиптәге җирләү турында таныклык;

3) гамәлдәге кабергә көл салынган урнаны күмгән очракта (гариза бары тик җирләү урыны өчен җаваплы заттан гына кабул ителә):

- үлү турында таныклык яки билгеләнгән үрнәктәге перинаталь үлем турында медицина таныклыгы;

- җирләү урыны өчен җаваплы затның паспорты;

- билгеләнгән үрнәктәге җирләү турында таныклык;

- вафат булучының мәете кайсы крематорийда һәм кайчан кремацияләнү турында (гариза бирүчегә көлне бирү фактын раслый торган) белешмә;

4) исән вакытта ук, әлеге кабергә җирләү турында таныклыкка ия булган вафат булучыны җирләгән очракта:

- җирләү урыны өчен җаваплы затның үлү турында таныклыгы;

- җирләү урыны өчен җаваплы вафат булучыны җирләү вазыйфаларын үз өстенә алган затның паспорты;

- билгеләнгән үрнәктәге җирләү турында таныклык. Таныклык булмаган очракта, вафат булучыны җирләү Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә архив мәгълүматлары нигезендә башкарылырга мөмкин.

58. Җирләнүченең ире (хатыны), балалары, ата-аналары, уллыкка алынучылары яки уллыкка алучылары вафат булган һәм тиешле гариза белән җирләү урыны өчен җаваплы затның мөрәҗәгать итү мөмкинлеге булмаган очракта, гамәлдәге кабергә кабат җирләү турындагы карар вафат булучының якын туганының гаризасы нигезендә, вәкаләтле орган җитәкчесе тарафыннан кабул ителергә мөмкин.

59. Гамәлдәге кабергә кабат җирләү турында гариза зираттагы вәкаләтле орган вәкиле тарафыннан карап тикшерелә, шулай ук исәпкә алу мәгълүматлары тикшерелә, күздә тотылган күмү урынына барыла, теркәү мәгълүматлары фактик мәгълүматлар белән чагыштырыла һәм, алар тәңгәл килгән очракта, әлеге урында җирләүне башкару мөмкинлеге билгеләнә, шуннан соң җирләү урыны өчен җаваплы зат гамәлдәге кабергә кабат җирләү өчен риза булган очракта, гаризага тиешле килешенү билгесе куела.

Гамәлдәге кабергә кабат җирләү буенча килешенүне алу түбәндәге сәбәпләр буенча кире кагылырга мөмкин:

- җирләү урыны өчен җаваплы затның булмавы яки кабат җирләү өчен аның ризалыгы булмау;

- якын туганына үлү турында таныклыкның төп нөсхәсе яки архив белешмәсе булмау;

- күздә тотылган җирләү урынының фактик мәгълүматлары теркәлгән мәгълүматларга туры килмәү;

- янәшәдәге җирләү урыннарына комачаулык куркынычы янау;

- янәшәдәге кабер өсте корылмаларына зыян килү куркынычы янау;

- кабер казу эшләрен башкаручы затлар тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янау;

- зиратның тышкы төзекләндерү объектларына зыян килү мөмкинлеге.

60. Җирләү (кабат җирләү) турындагы гариза, зираттагы вәкаләтле орган белгече тарафыннан карап тикшерелгәннән соң, гариза вәкаләтле орган администрациясенә тапшырыла, анда гариза бирүченең җирләүне гамәлгә

ашыруга хокукы, тапшырылган документларның тулылыгы һәм тиешле килешенүләрнең булуы тикшерелә.

Зираттагы вәкаләтле орган белгеченең уңай килешенү билгесе булмаган очракта, килешенүне кире кагуның нигезлелеге тикшерелә.

61. Гариза бирүченең җирләүне гамәлгә ашыруга хокукын тикшерү тәмамланганнан соң, гариза бирүчегә кабер казу өчен рөхсәт бирелә яисә вәкаләтле орган вәкаләтле затының тиешле визасын кую юлы белән, рөхсәт бирү кире кагыла. Кабер казу өчен рөхсәт бирү кире кагылган очракта, гариза бирүче ачыкланган кимчелекләрне бетерергә һәм гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

62. Алынган рөхсәт буенча, гариза бирүче зираттагы вәкаләтле орган белгечләренә мөрәҗәгать итә, шуннан соң гариза бирүче һәм кабер казуны гамәлгә ашыручы затлар кабер казуның куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж узалар һәм, эшләр башкаруга рөхсәт бирү журналына имза куеп, зират инфраструктурасына һәм күршедәге җирләү урыннарына зыян китергән өчен шәхси җаваплылык турында кисәтеләләр.

63. Кабер казу 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр гамәлгә ашырыла.

Эшләр башкару өчен, вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган зат һәм турыдан-туры кабер казуны гамәлгә ашырачак затлар зиратның эш режимын исәпкә алып кертеләләр.

64. Кайгылы процессия вакытында яисә кабер казу гамәлгә ашырыла торган җиргә якында җирләү башкарылган очракта, җир эшләре яки кабер өсте корылмаларын урнаштыру эшләре туктатыла.

65. Кабер казу эшләре тәмамланганнан соң, әзерләнгән кабернең санитар нормаларга һәм рөхсәт документларына туры килүе, шулай ук янәшә территориядәге чисталык һәм тәртип предметына вәкаләтле орган белгече тарафыннан тикшерелә. Туры килгән очракта гаризада билге ясала һәм аның нигезендә вафат булучыны җирләү өчен җирләү процессиясе рөхсәт ителә.

66. Вафат булганнарны җирләүне контрольдә тоту мөмкинлеген тәэмин итү һәм башка җирләү процессияләре белән туры килүен булдырмау максатында, вафат булучыны турыдан-туры җирләү вакыты вәкаләтле орган белгече тарафыннан күрсәтелә.

67. Җирләү тәмамланганнан соң, вәкаләтле орган белгече тарафыннан җирләү урынына барып, кабердә һәм янәшә территориядә тәртип, чисталык, санитария-эпидемиология таләпләренә туры килү, янәшәдәге җирләү урыннарының, кабер өсте корылмаларының һәм зират инфраструктурасының саклнышы һәм тынычлыгы предметына тикшерү үткәрелә, аннан соң кабер казуга рөхсәт язуында тиешле билге куела.

68. Вафат булучыны җирләгәнннән соң, барлык билгеләр куелган билгеләнгән тәртиптәге җирләү турында гариза вәкаләтле орган вәкиленә тапшырыла, ул җирләүне гамәлгә ашыру вазыйфасын үз өстенә алган затка җирләү турында таныклык бирү өчен нигез булып тора.

69. Вафат булучыны тиешле рөхсәттән башка яки билгеләнгән регламентларны бозып җирләгән өчен гамәлдәге законнарда каралганча җаваплылыкка тарту билгеләнгән. Вәкаләтле орган, вафат булучыны җирләү фактын дөрес итеп билгеләү һәм раслау мөмкинлеге булмау сәбәпле,

билгеләнгән тәртиптәге җирләү турында таныклыкны һәм зиратта вафат булучының җирләү урыны булу турындагы белешмәне бирү хокукына ия түгел.

5 бүлек. Хатыны (ире), якын туганнары, башка туганнары яисә вафат булучының законлы вәкиле булмаган вафат (һәлак) булганнарны җирләү

70. Вафат булучының ире (хатыны), якын туганнары, башка туганнары яисә законлы вәкиле булмаган яки алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаган очракта, шулай ук өйдә, урамда яки башка җирдә вафат булучыны җирләүне гамәлгә ашыру вазыйфасын үз өстенә алган башка затлар булмаган очракта, эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе ачыкланганнан соң аны җирләү, Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, үлү сәбәбен ачыклаган вакыттан соң өч тәүлек эчендә, сатулар нәтиҗәсе буенча, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә торган җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

71. Эчке эшләр органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта шәхесе ачыкланмаган вафат булучыларны җирләү, күрсәтелгән органнарның ризалыгы буенча, җәмәгать зиратларының шундый очраклары өчен билгеләнгән участокларда җирләү юлы белән, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

72. Җирләүне гамәлгә ашыру вазыйфасын үз өстенә алган зат булмаган очракта, яки алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаган очракта, эчке эшләр органнары тарафыннан өйдә, урамда яки башка җирдә вафат булучының шәхесе ачыкланганнан соң аны җирләү, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан зиратлар территориясендә теркәлгән һәм эшләп килүче җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтләрне килешү нигезендә җәлеп итеп, Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса, үлү сәбәбен ачыклаган вакыттан соң өч тәүлек эчендә гәүдәне (мәет калдыкларын) җирләү юлы белән, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла. Әлеге максат белән зиратларда эзләүчесе булмаган гәүдәне (мәет калдыкларын), шулай ук шәхесе ачыкланмаган вафат булучыларны җирләү өчен махсуслаштырылган участоклар булдырыла.

73. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта эчке эшләр органнары тарафыннан шәхесе ачыкланмаган вафат булучыларны җирләү, күрсәтелгән органнарның ризалыгы буенча, җәмәгать зиратларының шундый очраклары өчен билгеләнгән участокларда җирләү юлы белән, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6 бүлек. Җирләү урыннарын теркәү һәм яңадан теркәү

74. Яр Чаллы шәһәре зиратларындагы каберләр вәкаләтле орган тарафыннан мәҗбүри теркәлергә (кабат теркәлергә) тиеш.

Вәкаләтле орган башкарылган җирләүләрнең исәбен кәгазьдә һәм электрон рәвештә алып бара.

75. Җирләү урынын (каберне) теркәү, вафат булучыны җирләү процедурасы тәмамланганнан соң, вәкаләтле органның вазыйфаи заты тарафыннан Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә башкарыла.

Җирләүләрне теркәү кенәгәсе вәкаләтле органда 25 ел дәвамында саклана, аннан соң саклау өчен, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль архивына тапшырыла.

Хуҗасыз җирләү урыннары барлыкка килүне булдырмау максатында, җирләү урыннарын (каберләрне) бары тик вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган физик затларга гына теркәү рөхсәт ителә.

Вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган (җирләү урыны өчен җаваплы) зат җирләү урынын теркәү һәм исәпкә кую белән бәйле барлык мәсьәләләрне тәгәлләргә, шул исәптән тиешле документларны рәсмиләштерергә, җирләү процедурасы тәмамланганнан соң ук исәпкә алу язмаларын кертергә тиеш.

76. Җирләү урынын теркәгәннән соң, вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган затка билгеләнгән үрнәктәге җирләү турында таныклык, шулай ук Җирләүләрне теркәү кенәгәсендәге язма номерына туры килүче кабер өсте теркәү номерогы бирелә.

Вәкаләтле органның вазыйфаи заты җирләү процедурасы тәмамланганнан соң ук, җирләү урынында кабер өсте теркәү номерогын урнаштырырга яки аның вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган зат тарафыннан урнаштырылуын тикшерергә тиеш.

77. Җирләү турындагы таныклык, таныклыкта күрсәтелгән җирләү урыны белән эш итү хокукын раслаучы документ булып тора. Җирләү урыны өчен җаваплы затның яки, нотариуста расланган ышаныч язуы нигезендә, аның вәкиленең гаризасы буенча түбәндәге эшләр башкарыла:

- кабер өсте корылмаларын урнаштыру;
- җирләү урыны өчен җаваплы затның хокукларын һәм вазыйфаларын кабергә җирләнүченең башка затына тапшыру;
- минерализация процессы тәмамланганнан соң, вафат булучыны яки мәет калдыкларын гамәлдәге кабергә күмү;
- кабат җирләү (мәет калдыкларын эксгумацияләү һәм башка урынга күмү).

78. Вәкаләтле орган, кирәк булган очракта, әмма кимендә 25 елга бер тапкыр җирләү урыннарын мәҗбүри рәвештә план буенча кабат теркәүне башкара. Кабат теркәү процессында җирләү урыны өчен җаваплы затлар билгеләнә, теркәү мәгълүматлары яңартыла, кабер өсте корылмаларының торышы билгеләнә, җирләү турында яңа таныклык һәм яңа теркәлү номеры бирелә. Яңадан теркәүне үткәргәндә кызыксынучы затлар тиешле гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәләр.

79. Гражданнар мөрәҗәгате белән теркәү һәм кабат теркәү билгеләнгән үрнәктәге гариза һәм, күчермәләрен теркәп, түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

1) җирләү урыны өчен җаваплы затны алыштырмыйча, план буенча кабат теркәгәндә:

- билгеләнгән үрнәктәге җирләү турында таныклык;
- җирләү урыны өчен җаваплы затның паспорты;

2) жирләү урыны өчен гамәлдәге җаваплы затның гаризасы буенча яңа зат исеменә кабат теркәгәндә:

- билгеләнгән үрнәктәге жирләү турында таныклык;
- жирләү урыны өчен гамәлдәге җаваплы затның паспорты;
- жирләү урыны өчен яңа җаваплы затның паспорты;
- әлеге кабергә күмелүче яисә жирләү урыны өчен җаваплы зат белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар;

3) жирләү урыны өчен җаваплы зат үлү сәбәпле кабат теркәгәндә:

- билгеләнгән үрнәктәге жирләү турында таныклык;
- җирләү урыны өчен җаваплы затның үлү турында таныклыгы;
- гариза бирүченең паспорты;
- әлеге кабергә күмелүче яисә җирләү урыны өчен жаваплы зат белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар;

4) туганнары һәм башка гражданнар катнашыннан тыш, махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан жирләнгән, эзләүчесе булмаган яки ачыкланмаган вафат булучының каберен кабат теркәгәндә:

- эзләүчесе булмаган яки ачыкланмаган вафат булучының үлү турында таныклыгы;
- зираттагы вәкаләтле орган вәкиленнән, кабернең урнашу урыны һәм теркәү номеры күрсәтелгән, билгеләнгән тәртиптәге белешмә;
- гариза бирүченең паспорты;
- кызыксынучы туганының, вафат булучының үлү һәм жирләнү шартлары, жирләү вакытында үзенең булмау сәбәпләре күрсәтелгән гаризасы;
- әлеге кабергә күмелүче яисә җирләү урыны өчен жаваплы зат белән туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар.

80. Җирләү урыны өчен җаваплы зат вафат булган очракта, кабер әлеге кабергә жирләнгән туганы яки гариза белән вәкаләтле органга беренче булып мөрәҗәгать иткән жирләү урыны өчен җаваплы зат исеменә теркәлә.

Берьюлы ике һәм аннан күбрәк гариза кергән очракта, кабат теркәү турында карар кабул иткәндә өстенлек түбәндәге тәртиптә бирелә:

- ире, хатыны;
- балалары, ата-анасы, уллыка алынучылар, уллыкка алучылар;
- туганлык мөнәсәбәтләре өстенлеге тәртибендә башка туганнары.

Җирләү урыны кабат теркәлгәннән соң, туганлык мөнәсәбәтләре өстенлеге тәртибендә өстенлекле яисә тигез хокукка ия башка затлар барлыкка килгән очракта, алар арасында карар судка кадәр яисә суд тәртибендә кабул ителә.

Алдагы кабат теркәү турындагы карарны гамәлдән чыгару һәм жирләү урынын (каберне) яңа зат исеменә кабат теркәү, жирләү урыны өчен гамәлдәге җаваплы затның язмача гаризасы буенча вәкаләтле орган тарафыннан яисә суд карары нигезендә гамәлгә ашырыла, бу очракта элек бирелгән таныклыкны юкка чыгару турындагы карар күчермәсе кызыксынучы затка жибәрелә.

81. Кабат теркәү вакытында, җирләү урыны өчен гамәлдәге җаваплы зат турында архив мәгълүматлары вәкаләтле органда булмаган очракта, гариза бирүчегә түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

- гариза бирүченең паспорты;

- тиешле кабергә җирләнгән затларның үлү турында таныклыгы (архив белешмәсе);

- әлеге кабергә күмелгән затлар белән туганлыкны раслаучы документлар;

- вафат булучының әлеге зиратта җирләнү фактын раслаучы документлар;

- урнаштырылган кабер өсте корылмаларына милекчелек хокукын раслаучы документлар.

82. Җирләү урыннарын, әлеге кабергә күмелүче белән яки җирләү урыны өчен җаваплы зат белән туганлык мөнәсәбләренә ия булмаган затлар исеменә кабат теркәү рөхсәт ителми.

83. Җирләү урынын яңа зат исеменә кабат теркәү турында карар кабул ителгәннән соң, вәкаләтле орган тарафыннан Җирләүләрне теркәү кенәгәсенә тиешле язма кертелә.

Җирләү урыны өчен яңа җаваплы затка җирләү турында таныклык һәм теркәү номерогы бирелә. Җирләү турындагы элекке таныклык һәм номерок вәкаләтле органга тапшырыла һәм утильләштерелә.

Вәкаләтле органның вазыйфаи заты яңа кабер өсте теркәү номерогын, кабат теркәү тәмамланганнан соң ук җирләү урынына урнаштырырга яки аның җирләү урыны өчен җаваплы зат тарафыннан урнаштырылуын тикшереп торырга тиеш.

84. Билгеләнгән үрнәктәге таныклык югалган очракта, җирләү урыны өчен җаваплы затның гаризасы буенча, архив белешмәләре нигезендә аңа дубликат бирелә.

85. Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә мәгълүматлар яки вафат булучының җирләнү фактын раслаучы дәлилләр булган очракта гына, әлеге зиратта гамәлдәге җирләү урынын раслау өчен, җирләү урыны өчен җаваплы затка билгеләнгән үрнәктәге белешмә бирелә.

Җирләүләрне теркәү кенәгәсендә мәгълүматлар яки вафат булучының җирләнү фактын раслаучы дәлилләр булмаган очракта, җирләү урыны өчен җаваплы затка вафат булучының биография мәгълүматлары күрсәтелгән кабер өсте корылмасының булуы турында белешмә бирелә.

## 7 бүлек. Кабер өсте корылмаларын урнаштыру тәртибе

86. Яр Чаллы шәһәре зиратларында кабер өсте корылмаларын әзерләү һәм урнаштыру әлеге тәртиптә каралган шартларга һәм Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының гамәлдәге норматив актларына туры китереп гамәлгә ашырыла.

87. Каберләргә кабер өсте корылмалары (кабер ташлары, торбәләр, чардуганнар, чәчәклекләр, цоколь һәм башкалар), аларны әзерләү (сатып алу) документларын күрсәтеп, җирләү урыны өчен җаваплы затның вәкаләтле органга гаризасы буенча урнаштырыла яки башкага алмаштырыла.

88. Әзерләнә һәм урнаштырыла торган кабер өсте корылмалары башка җирләү урыннарына керүгә һәм зират территориясен төзекләндерүгә һәм агымдагы карап тотуга комачауларга тиеш түгел.

89. Кабер өсте корылмалары җирләү өчен билгеләнгән җир участогы чикләрендә урнаштырыла. Кабер ташларын, стелаларны, мемориаль такталарны, башка истәлек билгеләрен участоктан читтә урнаштыру тыела.

90. Очлы һәм кадаучы-кисүче элементлардан торган чардуганнарны урнаштыру тыела. Урнаштырылган кабер өсте корылмаларының участок чикләреннән чыгып яки алар өстендә асылынып торучы өлешләре булырга тиеш түгел.

Урнаштырыла торган кабер өсте корылмаларының биеклеге 2 (ике) метрдан, чардуганнарныкы – 80 см дан артырга тиеш түгел.

91. Зиратларда кабер өсте корылмаларын урнаштыру җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт көче белән яки, эшләр башкарыла башлаганчы һәм тәмамланганнан соң вәкаләтле орган белгечләре тарафыннан, аларны урнаштыру эшләрен үткәрү технологиясен контрольдә тотуны гамәлгә ашырып, башка затлар тарафыннан башкарыла.

Урнаштыру технологиясе үтәлмәү урнаштырылган кабер өсте корылмаларына, инженерлык челтәрләренә, аллея, юллар өслегенә, яшел утыртмаларга һәм башка тышкы төзекләндерү объектларына зыян (бозылу, юк ителү) китергән очракта, заказчы вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелгән кимчелекләр акты нигезендә, китерелгән зыянны тулы күләмдә капларга тиеш.

92. Туфрак утыру ихтималы булганга, кабер өсте корылмаларын вафат булучы җирләнгәннән соң кимендә бер ел узгач урнаштыру тәкъдим ителә.

93. Урнаштырылган кабер өсте корылмалары җирләү урыны өчен җаваплы затлар милке булып тора, шул сәбәпле аларга әлеге корылмаларны карап тоту һәм саклау бурычы йөкләнә.

94. Корылмаларны урнаштырган көнне, кабер өсте корылмаларын урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан Кабер өсте корылмаларын теркәү кенәгәсендә теркәлә, анда квартал, сектор, кабернең участок номеры һәм үлчәмнәре, җирләнгән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, ташны урнаштыру датасы, габарит үлчәмнәре һәм материалы, җирләү урыны өчен җаваплы затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме күрсәтелгән язмалар кертелә. Алар җирләү турындагы таныклыкка кабатлап языла.

95. Кабер өсте корылмаларына (ташларга) вафат булучы турында дөрес булмаган биография мәгълүматларыннан торган язмалар язу тыела.

96. Куелган таләпләргә туры килми торган кабер өсте корылмаларын урнаштырган җирләү урыны өчен җаваплы затлар яки гражданнар, кисәтүне алганнан соң 30 көн эчендә әлеге кимчелекләрне бетерү кирәклеге турында кисәтеләләр.

Башка каберләргә керүгә комачаулый торган чардуган урнаштырылган ташландык җирләү урыны өчен җаваплы затны билгеләү мөмкин булмаган очракта, вәкаләтле орган кызыксынучы затлар катнашында комиссия тикшерүе нәтиҗәләре буенча, башка каберләргә керүне тәэмин итү максатында ташландык җирләү урынының чардуганын өлешчә демонтажлау (күчерү) турында карар кабул итәргә хокуклы.

97. Кабер өсте корылмаларын корыган (авария хәлендәге) агачлар ауу, табигый бәла-казалар, урлау һәм вәхшилек нәтиҗәсендә ихтимал булган зыяннардан иминиятләштерү тәкъдим ителә.

## 8 бүлек. Каберләрне һәм кабер өсте корылмаларын карап тоту, каберләрне хуҗасыз дип тану

98. Үз исеменә җирләү өчен таныклык бирелгән затлар кабер өсте корылмаларын һәм яшел утыртмаларны (кабер өстен, ташны, цокольне, чәчәклекне, чардуганны, җирләү турында кирәкле мәгълүматларны) үз көчләре белән яисә, башка затларны җәлеп итеп, тиешенчә карап тотарга тиеш.

99. Кабер өсте корылмасы (кабер ташы), чардуган милекчесенең теләге буенча, күрсәтелгән милекче һәм җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт арасында кабер өсте корылмасын (кабер ташын), чардуганны саклауга кабул итү турында, җирләү урыннарына хезмәт күрсәтүгә килешүләр төзелергә мөмкин.

100. Җирләү турында мәгълүматлар (кабер ташы, цоколь, чардуган, вафат булучы турында мәгълүмат билгесе, тәре һ.б.) бөтенләй булмаган һәм рәттән 2 (ике) елдан артык җирләү урыны каралмаган очракта, зират администрациясе түбәндәгеләргә бурычлы:

1) кабернең торышы турында акт төзү өчен җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт, җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительлек советы вәкилләре катнашындагы комиссияне чакырырга;

2) җирләү урынына җирләү урынын тәртипкә китерү кирәклеге турында кисәтү трафареты урнаштырырга;

3) әлеге җирләү урынын махсус кенәгәдә теркәргә;

4) хуҗасыз җирләү урынының яки кабер өсте корылмасының тарихи-мәдәни кыйммәтен билгеләгән очракта, аның сакланышын тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне саклау һәм файдалану турындагы законнарга туры китереп тәэмин итәргә.

101. Кисәтелгәннән соң бер ел узуга кабер тәртипкә китерелмәгән һәм кызыксынучы зат гамәлдәге җирләү урыны өчен җаваплылыгын раслаучы документаль дәлилләрне тапшырмаган очракта, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган оешма җирләү эше мәсьәләләре буенча попечительлек советы вәкилләре белән берлектә, каберне һәм кабер өсте корылмасын хуҗасыз дип тану турында карар кабул итәргә хокуклы.

102. Кабер өсте корылмасы хуҗасыз дип танылганнан соң, вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган затка, каберне һәм кабер өсте корылмасын тәртипкә китерү кирәклеге турында заказлы белдерү хаты кабаттан җибәрелә, таләп үтәлмәгән очракта, акт төзелгәннән соң 3 елдан, әмма җирләү көненнән соң кимендә 20 ел узганнан соң кабер өсте корылмасы хуҗасыз дип таныла.

103. Кабер өсте корылмаларын сүтү тиешле акт белән рәсмиләштерелә.

104. Әлеге участокта кабат җирләү, кабер өсте корылмасы хуҗасыз дип танылганнан соң кимендә 10 ел узгач рөхсәт ителә.

105. Хуҗасыз каберләргә җирләү әлеге кагыйдәләргә туры китереп башкарыла.

## 9 бүлек. Зиратларга килү кагыйдәләре

106. Зиратлар территориясенә килүчеләр җәмәгать тәртибен һәм тынлыкны сакларга тиеш.

107. Зиратка килүчеләр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) вафат булучылар җирләнгән урынга килергә;

2) гыйбадәт билгеләнешендәге объектларга килергә;

3) җирләү урыннарын карап тотарга;

4) кабер ташларын һәм башка кабер өсте корылмаларын урнаштырырга, үзгәртергә, алырга, каберләрне төзекләндерү буенча нинди дә булса капиталь эшләр башкарырга, шул исәптән эскәмияләр урнаштырырга;

5) зират территориясенә транспорт чарасында керергә;

6) дини йолалар үткәрергә.

108. Дини гореф-гадәтләр дини оешмалар һәм конфессияләр тарафыннан билгеләнгән йолалар буенча, гражданнар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә үткәрелә һәм әлеге тәртипкә һәм башка хокукый актларга каршы килергә тиеш түгел.

109. Зират территориясендә түбәндәгеләр тыела:

1) йорт хайваннарын көтү, кошлар тоту, этләр белән йөрү;

2) учак ягу, ком һәм балчык алу, кәс кисеп алу;

3) җир казу;

4) кабер ташларын бозу, территорияне чүпләү;

5) яшел утыртмаларны сындыру, чәчәкләрне өзү;

6) велосипедта, мопедта, мотороллерда, мотоциклда йөрү, чаңгыда һәм чанада шуу;

7) спиртлы эчемлекләр эчү, психотроп чаралар һәм наркотиклар куллану, алкоголь һәм башка чара кулланып, исерек хәлдә булу;

8) территорияне металл ватыклары, төзелеш һәм көнкүреш калдыклары һәм башка материаллар белән тутыру һәм чүпләү;

9) хайваннарны күмү һәм корбан чалу;

10) җирләү урыннарында агачлар һәм куаклар утырту;

11) зират ябылганнан соң аның территориясендә йөрү;

12) чит мөлкәтне үзләштерү, аны урыныннан күчерү һәм үз белдеге белән башка гамәлләр кылу.

110. Зиратлар территориясендә эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру (чәчәкләр, җирләү йоласы предметлары, каберләрне төзекләндерү буенча материаллар сату) тыела. Эшмәкәрлек эшчәнлеген Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан алынган рөхсәт нигезендә, бары тик махсус билгеләнгән урыннарда гына гамәлгә ашырырга мөмкин.

111. Җирләү урыннарын мәсхәрә иткән яки юкка чыгарган өчен Россия Федерациясе законнарында каралганча җаваплылыкка тарту билгеләнгән.

112. Вафат булучыны җирләү вазыйфасын үз өстенә алган (җирләү урыны өчен җаваплы) затлар түбәндәгеләргә бурычлы:

1) тиешле документларны рәсмиләштерергә һәм җирләү процедурасы тәмамланганнан соң ук җирләү урынында кабер өсте теркәү номеры урнаштырылган булуга инанырга;

2) утильләштерү өчен, элекке җирләү урынын вәкаләтле органга тапшырганнан соң аны кабат теркәгән очракта, яңа кабер өсте теркәү номерының җирләү урынында урнаштырылган булуына инану;

3) каберне, кабер өсте корылмаларын, яшел утыртмаларны һәм җирләү турында кирәкле мәгълүматларны тиешле хәлдә тоту;

4) үз вакытында кабер өстен төзәтү, үләнен чабу, кабер өсте корылмаларын ремонтлау һәм буяу, чүпне махсус билгеләнгән урыннарга (контейнерларга) чыгарып, периметр буенча 0,5 метр аралыкта янәшә территорияне чистарту;

5) план буенча кабат теркәлү.

113. Дини оешмаларның вәкилләре үзләренең һәм башка конфессия вәкилләренә хөрмәт белән карарга, йолалар үткәрүгә комачауламаска, җирләүне оештыруны һәм үткәрүне гамәлгә ашыручы оешма персоналына җирләү церемониясе үткәргән вакытта үз функцияләрен башкаруда ярдәм күрсәтергә тиеш.

114. Кабердәге предметларны, кабер өстендәге ритуаль атрибутларны урлауда, җирләү урыннарын мәсхәрә итүдә һәм юкка чыгаруда гаепләнгән затлар Россия Федерациясе законнарында каралганча җавапка тартылалар.

## 10 бүлек. Зиратлар территориясен карау буенча иҗтимагый чаралар

115. Зиратлар территориясен карау буенча төп иҗтимагый чаралар (шимбә һәм чәршәмбе өмәләре) бәйрәм һәм истәлекле даталар (Яз һәм хезмәт бәйрәме, Җиңү көне), дини бәйрәмнәр һәм истәлекле даталар (Пасха, Радоница, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме һәм башкалар) алдыннан, ел саен апрель һәм май айларында, сентябрь һәм октябрь айларында Башкарма комитет тарафыннан оештырыла.

116. Җирле үзидарә органнары һәм зиратларга хезмәт күрсәтүче оешмалар, җыештыру инвентаре һәм махсус техника бирү юлы белән, зиратларда шимбә һәм чәршәмбе өмәләре үткәрүдә инициатива күрсәтүче төркемнәргә һәм берләшмәләргә ярдәм күрсәтәләр.

117. Зиратлар территориясен карау буенча иҗтимагый чаралар оештыруны Яр Чаллы шәһәренең Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

## 11 бүлек. Яр Чаллы шәһәренең дини зиратларындагы эшчәнлекне оештыру

118. Әлеге бүлек Яр Чаллы шәһәрендәге дин тотучы гражданнарның һәм вафат булганнарның якын туганнарының дини зиратта тиешле дини гореф-гадәтләр буенча шул ук диндәге алдан вафат булучылар белән янәшә җирләнү хокукларын яклый.

119. Дини зират – бер диндәге (конфессиядәге) вафат булучылар өчен җирләү урыннарыннан, шулай ук вафат булганнарны җирләүне гамәлгә ашыру һәм ритуаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән биналар, корылмалар һәм башка объектлардан торган җирләү билгеләнешендәге объект.

120. Яр Чаллы шәһәрендәге дини зиратлар, уставларында дини йолаларны зиратларда гамәлгә ашыру күздә тотылган үзәкләштерелгән дини оешмалар тәкъдиме буенча оештырылырга мөмкин.

Дини зират оештырылганнан соң аның статусын җәмәгать статусына яки башкага үзгәртү рөхсәт ителми.

121. Дини конфессияләр карамагындагы төзелешләр өчен җир участоклары үзенә аерым булып тора, алар уникаль кадастр номерына ия һәм дини оешмаларга Россия Федерациясе законнарында каралган хокукта һәм срокка бирелә.

122. Дини зиратларның эшчәнлек тәртибе, тиешле дини берләшмәләр белән килешенеп, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм жирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
1 нче кушымта

# ЖИРЛӘҮ ӨЧЕН ГАРИЗА

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитет Җитәкчесе ______________________________

Кемнән ______________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________________________________

_______________________________________________________________________
(яшәү урыны)

## ГАРИЗА

Вафат булган туганым ____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________ елда минем вафат булган туганым

_______________________________________________ жирләнгән урында
(туганлык мөнәсәбәте, фамилиясе, исеме, атасының исеме)

______________________________ зиратның №_______________ участогында
(исеме)

_______________________________________________ жирләүне сорыйм.
(кая, кардәшләр каберенә яки буш урынга)

Кабердә _______________________________________________ язылган
(элек жирләнгән вафат булучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________ бар.
(кабер ташының яки трафаретының торе күрсәтелә)

Мәгълүматларның дөреслеге өчен жаваплылыкны үз өстемә алам.

«____» __________20__ ел. Шәхси имза __________________________

Искәрмә – Гариза бары тик язу карасы белән тутырыла.

ЗИРАТ АДМИНИСТРАЦИЯСЕНЕҢ НӘТИҖӘСЕ

«____» ____________ 20_ ел                    Администраторның имзасы ____________________

Чардуган _______________ үлчәмдә рөхсәт итәлергә мөмкин

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм җирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен
тәэмин итү идарәсе башлыгы

______________________________
(Ф.И.А.и.)

______________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

______________________________

______________________________
(почта адресы, телефоны, факсы)

Кабат җирләүне башкару өчен рөхсәт бирүгә
**ГАРИЗА**

______________________________ вафат булган,
(үлү датасы)

______________________________ җирләнгән,
(җирләү урыны)

______________________________
(физик затлар өчен вафат (һәлак) булучы белән туганлык дәрәҗәсе,
вафат булучының Ф.И.А.и.)

______________________________ сәбәпле
(кабат җирләү сәбәбе, нигезе)

______________________________
(кабат җирләү урыны)

кабат җирләү өчен рөхсәт бирүне сорыйм.

Кабат җирләүгә каршы башка туганнар юк. Бирелә торган мәгълүматларның тулылыгы һәм дөреслеге өчен тулы җаваплылыкны үз өстемә алам.

Рөхсәт алу өчен кирәкле документлар теркәлә.

Кушымта: ______ биттә.

| | | |
|---|---|---|
| ____________ | ____________ | ____________ |
| (дата) | (имза) | (имзаның расшифровкасы) |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм җирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә

Җирләүләрне теркәү кенәгәсе

Титул бите

______________________________________________

күму һәм җирләү эше өлкәсендә

______________________________________________

җирле үзидарә вәкаләтле органының исеме

ЖИРЛӘҮЛӘРНЕ ТЕРКӘҮ
КЕНӘГӘСЕ №__

______________________________________________

(торак пунктның исеме)

______________________________________________

(зиратның исеме)

Башланды «__» __________ 20__ ел
Тәмамланды «__» __________ 20__ ел

Җирләүләрне теркәү кенәгәсенең титул бите формасы

А4 форматы (210 х 297 мм)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм җирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
4 нче кушымта

# Җирләүләрне теркәү кенәгәсе

| Регистр № | Вафат булучының Ф.И.А.и. | Вафат булучының яше | Үлү датасы | Җирләү датасы | Гражданнар хәле актларын теркәү идарәсеннән үлү турында таныклык № | Таныклыкны биргән гражданнар хәле актларын теркәү идарәсе | Җир казучының фамилиясе | Участок № | Җирләү өчен җаваплы затның Ф.И.А.и. моб.телефоны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм жирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
5 нче кушымта

Теркәү кенәгәсенең титул бите формасы

# Кабер ташларын һәм чардуганнар урнаштыруны теркәү кенәгәсе

_________________________________________________________ шәһәре
(исеме)

_________________________________________________________ зираты
(исеме)

Башланды «___» ____________________20___ ел.

Тәмамланды «___» ____________________ 20___ ел.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
территориясендә ритуаль хезмәтләрне
оештыру һәм җирләү урыннарын
карап тоту тәртибенә
6 нчы кушымта

# Кабер ташларын һәм чардуганнар урнаштыруны теркәү кенәгәсе

(кенәгәнең бите) А4 форматы (210 х 297 мм)

| Т/с | Җирләнүченең Ф.И.А.и. | Кабер ташын әзерләүченең документы | Урнаштыру датасы | Квартал номеры | Сектор номеры | Кабер номеры | Кабер ташының материалы һәм үлчәмнәре | Чардуганның материалы һәм үлчәмнәре | Кабер ташын урнаштыруга рөхсәт, кабер өчен җаваплы затның Ф.И.А.и. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |